

Авыр эпидемиологик хәл безгә Боек Жинvнен 75 еллыгын зур бәйрәм буларак билгеләп vтәргә комачаулады, әмма без, һичшиксез, кулдан килгәннен барысын да эшләячәкбез. Алда тулы бер уку елы. Безне дә патриотик юнәлештәге чираттагы акцияләр һәм чаралар котә. Башкача була да алмый, без бит педагоглар, яшь гражданнарны Ватаныбызнын чын патриотлары итеп тәрбияләргә тиеш.      Кадошкино районы Большие Поляны гомуми белем бирvче топ мәктәбебездә, илнен барлык уку йортларындагы кебек, 2020-2021 уку елынын беренче уку коне ук инде патриотик тәрбия рухында vтеп китте. Беренче сентябрь конне барлык сыйныфларда да “Истә тотарга – димәк белергә!” (“Помнить – значит знать!”) дигән девиз астында Жинv Дәресләре узды. Ә икенче сентябрь конне, Икенче ботендонья сугышы тәмамлану тантанасы алдыннан, безнен барлык тәрбияләнvчеләребез дә илебез тарихына онлайн-экскурсия ясадылар. Ни очен Икенче ботендонья сугышы Берлинда тәмамланмый? Ни очен СССР Япония белән сугышка керергә мәжбvр булган? 40 елдан сон Россиягә кайсы территорияләр кvчте? Ни очен хәзер сугыш тәмамлану коне дип 3 сентябрь игълан ителде? Барлык сорауларга да Ботенроссия хәрәкәтенен яшь тарихчылары һәм остазлары булган «Жинv волонтерлары» жавап бирде.

Чаралар чылбыры Боек Ватан сугышы фронтларында һәлак булган авылдаш-ларыбыз һәйкәленә чәчәкләр салу белән дәвам итте. Сvз унаеннан әйтергә кирәк, балалар алдында хәзер ор-яна тос алган һәйкәлебез басып тора. Монументнын барлык элементлары да бик яхшы рес-таврацияләнгән, арткы план диварындагы мәрмәр такталарда Боек Ватан сугышы кырларында мәнгегә ятып калган якташларыбызнын исемнәре урын алган. Монумент территориясе бетон плитәләр белән жәелгән. Бюджет олкәсендә эшләvчеләрнен кайгыртучан куллары белән периметр буенча матур чәчәкләр утыртылган. Бу матур композиция хәзер авылыбызнын Yзәген бизи.

Әлегә кадәр монументыбыз жимерек хәлдә иде. Безнен авыл жирлеге житәкчесе Наилә Хафиз кызы Долотказина әлеге һәйкәлне реконструкцияләv инициативасы белән чыккан иде. Аны кvпләр хуплады: безнен район башлыгы А.В.Чаткин һәм Мордовия Госсобраниесы депутаты, “Мир цветов” жәмгыятьчелеге генераль директоры А.А.Болдырев, якташыбыз «ЭМ-КАТ» генераль директоры К.Ш.Мангутов.

Аерым хормәт белән моһим эштән, Боек Ватан сугышы фронтларында һәлак булган якташларыбыз истәлегенә куелган һәйкәлне реконструкцияләvдән читтә калмаганнарга, битараф булмаган барлык кешеләргә Большие Поляны авыл жирлеге администрациясе белән авылдашларыбыз ихлас рәхмәтләрен белдерәләр. Бу шундый оешмалар: район главасы Андрей Викторович Чаткин аша Кадошкино муниципаль районы хакимияте, ООО

генераль директор Камиль Шәvкәт улы Мангутов аша «ЭМ-КАТ» җәмгыятьчелеге белән Мордовия Госсобраниесе депутаты, АО генераль директоры Александр Александрович Болдырев аша «Мир цветов» җәмгыятьчелеге; Большие Поляны топ гомуми белем бирv мәктәбе укытучылары коллективы һәм авыл жирлеге администрациясе; ИП Р.Ш.Кильдеев; ИП Р.Х.Кильдеев; ИП Р.А.Долотказин. Шәхси затлар: Камиль Шәvкәт улы Мангутов; Александр Владимирович Куликов; Артур Наиль улы Мангутов; Ильдус Ростәм улы Кильдеев; Рауф Вәли улы Долотказин; Наиль Халил улы Долотказин; Радик Рафаэль улы Долотказин; Равил Ринат улы Иштряков; Руслан Альберт улы Долотказин; Рафаэль Ибраһим улы Долотказин.
Безнен һәрберебез очен бу изге эшкә бәһасез олеш керткәннәре очен барлык ирекле ярдәмчеләргә чын кvнелдән рәхмәтебезне белдерәбез.

**Светлана АБАЕВА**